СОВЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Чехова, д.18, с. Верхний Услон,
422570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ
Чехов ур., 18 нче йорт, Югары ослан авылы,
422570

Тел.: (84379) 2-13-38, факс: (84379) 2-18-39. E-mail: sovet.uslon@tatar.ru, verhniy-uslon.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

27.08.2018 с. Верхний Услон № 36-403

**Югары Ослан муниципаль районы белем бирү учреждениеләренең яңа 2018-2019нчы уку елына әзерлеге турында**

“Югары Ослан муниципаль районы мәгариф бүлеге”МКУ җитәкчесе Л.В.Абрамованың Югары Ослан муниципаль районы белем бирү учреждениеләренең яңа 2018-2019нчы уку елына әзерлеге турында белдерүен тыңлап һәм фикер алышып,

**Югары Ослан муниципаль районы Советы**
**Карар кылды:**

1. Югары Ослан муниципаль районы белем бирү учреждениеләренең яңа
2018-2019нчы уку елына әзерлеге турында белдерүен исәпкә алырга.

2. Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетына:

- төзелеш, янгынга каршы нормалар һәм кагыйдәләр, укучыларның, тәрбияләнүчеләрнең һәм белем оешмалары хезмәткәрләренең сәламәтлеген саклауда санитар һәм гигиена нормалары, уку бүлмәләренең җиһазлау һәм уку процессын җиһазлау дәрәҗәсе, педагогик хезмәткәрләрнең белем дәрәҗәсе һәм мәктәпләрне комплектлаштыруга таләпләр белән туры китереп Югары Ослан муниципаль районы белем бирү учреждениеләренең яңа
2018-2019нчы уку елыда эшләүен тәэмин итергә;
- белем бирү оешмаларында уку җиһазларын, уку-күрсәтмә әсбапларын саклау һәм нәтиҗәле файдалануны контрольдә тотуны тормышка ашырырга;
- канун таләпләре белән туры китереп, балаларны тору урыныннан белем бирү оешмасына кадәр ташуны оештыру буенча чаралар күрергә;
- белем бирү оешмалары укучыларының сәламәтлеген саклау һәм ныгыту , туклануын оештыру өчен кирәкле шартлар тудыру буенча чаралар күрергә;
- районның белем бирү оешмаларында укучыларның куркынычсызлыгын булдыру буенча чаралар күрергә.

3. Авыл җирлекләренең башкарма комитетларына :

- белем бирү оешмалары урнашкан урыннарда юл хәрәкәте куркынычсызлыгын булдыру максатыннан белем бирү оешмаларына караган территорияләрне тикшерү буенча, кисәтүче юл билгеләре, тамгалар булдыру буенча чаралар күрергә, кирәк вакытта “Балалар” юл билгеләрен урнаштыруны һәм яңартуны, билгеләр ясауны тәэмин итергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Югары Ослан муниципаль районы Советының иҗтимагый –мәдәният һәм яшьләр эшләре комиссияләренә тапшырырга.

**Совет рәисе,**
**Югары Ослан**
**муниципаль районы Башлыгы** **М.Г.Зиатдинов**